

# ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ | № 11 (26) | 8 ИЮНЯ 2010



# ГАЛИГӘ БАРДЫК ӘЛЕ...



29 нчы май көнне Самара өлкәсе Похвистнево районы Гали авылында татар тарихында беренче тапкыр I Бөтенрусия авыл Сабан туе узды. Татарстан, Чуашстан, Марий Эл, Мордовия, Удмуртия республикалары, Киров, Ульян, Оренбург, Төмән, Свердловск, Түбән Новгород, Чиләбе, Тамбов, Пенза, Пермь, кыскасы, Русиянең утызга якын төбәк вәкилләре, Кытай Халык Республикасыннан килгән татар оешмалары делегацияләре зур мәйданны тутырдылар. Мәчет манарасыннан яңгыраган азан тавышы астында алар мәйдан тирәли уздылар. Гали авылы Сабантуенда мактаулы кунаклардан РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Александр Жуков, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Григорий Рапота, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Самара өлкәсе губернаторы Владимир Артяков чыгыш ясады. Шулай ук әлеге чарада РФ мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров катнашты.

Рөстәм Миңнеханов Гали авылында яшәүчеләргә Татарстан җитәкчелеге һәм барлык татар халкы исеменнән сәламнәрен җиткереп, әлеге авылның яшәешен күреп гаять гаҗәпләнүен белдерде. «Хуҗалыклар нык, халкы тырыш, бөтен авылларга үрнәк авыл ул — Гали,» — диде Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында һәм авылга киләчәктә дә уңышлар, Сабан туеның күңелле, ямьле үтүен теләде. ТР Президенты өлкә губернаторы Владимир Артяковка мөрәҗәгать итеп, ил күләмендәге шундый чара оештырган өчен рәхмәт әйтте һәм Татарстан исеменнән Гали авылы җирле үзидарәсенә «Фиат Дукато» автомобиле бүләк итте. Ул шулай ук Самара өлкәсе Похвистнево районы хакимияте башлыгы Александр Ларионовка, шәхси эшмәкәр Расих Латыйповка Казан белән ике арада мәдәни һәм икътисади элемтәләрне ныгытуда керткән өлешләре өчен «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләрен тапшырды. Самара өлкә «Туган тел» җәмгыяте вице-президенты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы Фәхретдин Канюкаев, Татарстан Республикасы белән Самара өлкәсе һәм халыклар арасындагы элемтәләрне ныгытканы өчен, ТР Президентының Рәхмәт хатына лаек булды. Рөстәм Миңнеханов Гали авылына шулай ук күп санлы китаплар бүләк итте.

Бәйрәм кунакларына Самара өлкәсе губернаторы Владимир Артяков та котлау сүзләрен ирештерде. «I Бөтенрусия авыл Сабан туеның Самара өлкәсендә узуы — зур мәртәбә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та, башка төбәк җитәкчеләре дә биредә. Бу көннәрдә үзенең 400 еллыгын билгеләп үткән Гали авылы, һичшиксез, тагын 400 ел яшәячәк әле, чөнки биредә уңган халык гомер итә,» — диде ул. В.Артяков авыл мәктәбенә, иң заманча спорт җиһазлары алу өчен, өлкә исеменнән сертификат бүләк итте.

Сабан туе ат чабышлары, җыр-биюләр, төрле уен, конкурслар белән дәвам итте.

Әлеге Сабантуйда иң мөһиме: татар авылының киләчәктә нинди модельдә яшәп сакланып калуы ачык чагылды. Мәгълүм ки, соңгы елларда авылларны торгазу йә инвесторлар, йә фермерлар тырышлыгы белән генә башкарыла дигән нәтиҗәгә килә башладык. Күрәсең, бу бердән бер генә юл түгел. Әгәр дә авыл кешесе табышлы хезмәт башкарып базар мөнәсәбәтләренә яраклаша икән, үз-үзен, гаиләсен тулысынча тәэмин итә ала. Ә бу инде — яңа шартларда төпле адым ясау дигән сүз. Берничә ел элек оешып аякка басып килгән Бөтенрусия авыллар ассоциациясе бу игелекле эшне әйдәп баручы көчкә әверелсен иде. Гали авылыннан Сабантуй эстафетасын кабул итеп алган атаклы Шыгырдан да киләчәк бәйрәмне шундый ук югары кимәлдә уздырыр дип ышанасы килә.

**(Из сайта ВКТ )**

**На снимке:** председатель Исполкома Всемирного Конгресса татар Ринат Закиров (справа) во время встречи с руководителями районных объединений татар Расихом Латыповым (Алькино), Ильдусом Давлятовым (Асекеево), Ильгизаром Зариповым (Абдулино).

**Фоторепортаж о праздновании сабантуя читайте на 2 стр.**

# Кечкенә Сабантуй

**4 июнь көнне Әсәкәйнең өченче балалар бакчасында сабантуй үтте. Балалар сабантуе дип аталса да, бу чара зур бәйрәмнәрдән бер дә ким булмады.**

Җәй — сабантуйларның гөрләп торган чагы. Аны яше дә, карты да игътибарсыз бер кайчан да калдырмый. Борынгыдан килгән халкыбызның олы бәйрәмнәрнең берсен, егерме беренче гасырларда ничек югалтмыйча саклап калырга? Әлбәттә, киләчәк буыннар аша. Кечкенәдән милли хисләрне уятып, милли горурлык тәрбияләп кенә, халыкның гореф гадәтләрен еллар аша тукмичә саклап калырга мөмкин.

Әсәкәйнең өченче балалар бакчасында татар мәдәниятенә бик зур игътибар бирелә. Монда эшләүче, этно-мәдәни эшне алып баручы Марзия Хуснутдинова әйтүе буенча, балаларны кечкенәдән инсафлы, әдәпле, мәрхәмәтле итеп тәрбияләү — әти-әниләр белән тәрбиячеләрнең җаваплы һәм изге бурычы. Кечкенәдән калфак, түбәтәй киеп үскән балалар үз халкының йолаларын алдагы гомердә дә саклар дип ышанып кала тәрбияче.

Шул йолаларның берсе — Сабантуе. Бу балалар бакчасында зур итеп, шау — гөр килеп, үткәрәләр. Җырлар, шигырьләр, биюләр — берсен дә онытып калдырмадылар.





Әлеге бәйрәмгә Хуҗа Насретдин да кереп чыкты. Бухара базарыннан алып кайткан баллы бүләкләре иң оста чүлмәк ватучыларга гына эләкте.

Ә мәйданда инде уеннар башланды. Кемдер капчык киеп сикерә, кемдер йомырка тотып чаба. Икенче якка карасаң, атлар чабышы, капчык белән сугышу. Ә мәйдан уртасында, әлбәттә, көрәшчеләр. Тырыш малайлар, уңган кызлар, хәтта, кунакка килгән әти-әниләр, әби-бабайлар — барысы да катнашты, берсе дә бүләксез калмады.

Өченче балалар бакчасы башкарылган эшендә бу бәйрәм әле бер тамчы гына. Инде егерме елдан артык, Рәйсә Байбикова җитәкчелегендә милли мәдәниятне үстерүдә зур эш алып барыла. Мондагы балалар Сөмбелә бәйрәме, Нәүрүз, Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре белән таныш. Алар туган телне өйрәнәләр. Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай кебек халкыбызның бөек улларын да онытмыйлар.

Балаларны милли рухта тәрбияләү — киләчәккә кайгырту. Чөнки халкыбызның киләчәге, аның булачак йөзе – безнең нәниләрдән тора.

**Алсу ХАФИЗ.**

# Сабантуй в «Алге»

Продолжается череда областных, районных, сельских сабантуев. В прошедшую субботу это мероприятие было проведено ОАО «Алга» в селе Новосултангулово Асекеевского района. Это крепкое, стабильное хозяйство возглавляет Ильдус Давлятов — депутат Законодательного Собрания Оренбургской области. Под стать статусу хозяйства и сабантуй. Мероприятие было зрелищным и интересным. Сельчане и гости отдохнули от души. Лучшие труженики хозяйства были поощрены. Хозяев и гостей сабантуя поздравил глава администрации района Николай Макаров. (Фоторепортаж об этом мероприятии читайте в следующем номере).

Ну а районный сабантуй в Асекеево состоится 12 июня.

САБАНТУЙ

# ГАЛИ-АВЫЛЫ СОБРАЛ ГОСТЕЙ




**Первым быть нелегко, особенно организуя такое мероприятие как Всероссийский сельский федеральный сабантуй. Но алькинцы справились с этой задачей, заодно научив гостей произносить правильно татарское название села — Гали авылы.**

Даже небесная канцелярия благоволила алькинцам. После дождей установилась хорошая, чуть прохладная погода. В самый раз для таких мероприятий на открытом воздухе.

Как сообщила пресс-служба Правительства Самарской области, на празднике плуга побывали 29 мая около 18 тысяч человек. Приехали делегаты из 23 регионов России и даже из других стран. В том числе и из Оренбургской области. Каждому такому гостю вручили пакет с подарками: бейсболку с символикой сабантуя, сувенир и книгу «Сохраняя вековые традиции», посвященную 400-летию Гали авылы. Надо отметить, что делегатов прибывших еще 28 мая, встречали радушно. Накормили, обеспечили ночлег.

На следующий день утром можно было наблюдать нескончаемую вереницу машин, прибывающих на сабантуй. Ну и с появлением вертолетов VIP-персон движение вовсе закрыли. Образовались километровые заторы. Так что многие попали на сабантуй после открытия праздника. А в церемонии открытии сабантуя приняли участие заместитель председателя правительства РФ Александр Жуков, полномочный представитель президента РФ в ПФО Григорий Рапота, губернатор Самарской области Владимир Артяков, президент Республики Татарстан Рустам Минниханов.

Правда, из-за обеспечения безопасности высоких гостей мы испытали некоторые неудобства, но это ничто по сравнению со зрелищностью праздника.

После обращения гостей заслуженный мастер спорта, чемпион СССР и Европы по дзюдо Хабиль Бикташев и председатель татарского культурно-просветительского общества «Туган тел» Похвистневского района Расих Латыпов подняли флаг России. Прозвучал гимн страны, и Сабантуй был объявлен открытым, после чего гости разошлись по разным площадкам праздника.





Жаль, что большинство зрелищ было объединено в один большой майдан. Внутри круга выступали артисты, в том числе знаменитые, тут же проходили схватки борцов, бегали с коромыслом конкурсантки и доставали монетки из чашки с катыком. Внутрь круга зрителей не пускали, вот и приходилось наблюдать за всем издалека. В преимуществе были только журналисты.





А вот выступление акробатов на семнадцатиметровом столбе видели все и были поражены смелостью атлетов — отца и сына. Причем, они не использовали страховку.

Конечно, гвоздем сабантуя стала национальная борьба керэш. В упорной борьбе звания батыра — лучшего борца Сабантуя — был удостоен Айнур Ахметзянов из Казани. Он и получил главный приз — автомобиль Тайота.

Гостей привлекли и конноспортивные соревнования. Ну, а юные могли покататься на пони.

Концерт был организован на малой и большой сценах. Выступали и наши земляки, в том числе и ансамбль «Чишма» из Асекеева. А вели концерт узнаваемые лица — работники ТНВ.

Привлекала зрителей выставка — распродажа изделий народного творчества.

Понравился огромный стенд, посвященный 400-летию Гали авылы. На нем размещены были фотографии сельчан.

Еще надо отметить, что спиртное на территории сабантуя не продавалось, что соответствовало духу этого народного праздника.

Словами не передать всю атмосферу и зрелищность праздника. Может, как-то помогут фотоснимки, ну а вернее всего побывать на сабантуе и увидеть все своими глазами.





**На снимках:**
Первый Всероссийский сельский сабантуй.

НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО




**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН**
**Иске Мөъмин авылы, Әсәкәй районы.**

**(Дәвамы. Башы 6-10 нчы саннарда).**

## Сигезенче бүлек

Матур җәй үтеп
Көзе дә җитте.
Кызый егетен
Көн саен көтте.

Әтисе үлгәч
Сатты малын да.
Кош-корты гына
Калды янында.

Урын тапмады,
Чиргә салышты.
Беркөн шулай да
Алар кавышты.

Егете килгән
Хәлен белергә.
Үткәрде алар
Шул төнне бергә.

Егет сөйләде
Үз күргәннәрен.
Әтисен ничек
Үтергәннәрен.

Таң аткач егет
Юлга кузгалды.
Ашарга аз гына
Кулына алды.

Кызы озатып
Калды урманда.
Нинди гүзәллек
Күзләрен анда.

Төннәр артыннан
Көннәр тиз үтте.
Коштан соң ямьле
Язы да җитте.

Апрель аеның
Егермеләре.
Немецларның да
Бик шат йөзләре.

Мәктәп өчендә
Уйный музыка.
Мондый тамаша
Түгелдер юкка.

Шәһәрдән килгән
Кунаклар да бар.
Ашы да пешә,
Кайный самавыр.

Шушы авылның
Полицайлары да,
Хатыннар белән
Җыелган монда.

Баксаң, Гитлерның
Туган көне икән.
Бу бит уңай чак
Күптәннән көткән.

Кызый да шунда
Аларга булыша.
Аш-су тарата,
Савыт юыша.

Стеналарда
Гитлер фотосы.
Ул немецларның
Явыз әтисе.

Төн җитеп килә,
Өй эче гөрли.
Нәрсә күрәсен
Алар бит белми.

Кайберәүләре
Инде исергән.
Йокларга диеп
Бүлмәгә кергән.

Икенчеләре
Ауган идәнгә.
Айныклары
Таралган өйгә.

Һәммәсе исереп
Тирә-як тынгач.
Кызый кузгалды
Тышка ялангач.

Сарайга кереп
Керосин алды.
Өй почмакларына
Бүлгәләп салды.

Калган өлешен
Сипте өстенә.
Шырпы кабызды,
Өй яна менә.

Утның ялкыны
Күккә терәлде.
Уянды халык,
Этләр дә өрде.

Өйнең эчендә
Акырышалар.
Төмүгә утында
Яндылар алар.

Икенче көнне
Килде тикшерү.
Халык җыйдылар
Элеп белдерү.

Унлап кешене
Кулга алдылар.
«Кемнең эше бу»
Дип ялындылар.

Әлеге дә шул
Сатылганнары
Чактылар. Утта
Янсын җаннары.

Ул гына төрткән,
Имеш үч итеп.
Өйгә килделәр
Кайтканын көтеп.

Кызый да шулай,
Эләкте төрмәгә.
Сорау алалар,
Тими әлегә.

Шәһәрдән килгән
Тикшерүчеләр.
Егетең кайда,
Әйтеп бир диләр?

Сорау алганнар
Кыздан көн саен.
Кыйнаганнардыр да,
Бәлкем, мөгаен.

Этләсәләр дә,
Егетен сатмады.
Эчтәге серен,
Эчтә саклады.

Шулай ай үткәч,
Көннәрнең бере.
Алып кайттылар
Авылга кире.

Ябып куйдылар
Сарай эченә.
Әллә нәрсәләр
Керде төшенә.

Ишек алдында
Казып багана,
Ясадылар
Аңа тагана.

Нечкә бер аркан
Куйдылар элеп.
Әйтеп йөрделәр
Өй саен кереп.

Җыйдылар халык
Якшәмбе көнне.
Үткәрде кызый
Йокламый төнне.

Менә таң атты,
Кояш күренде.
Биш-алты кеше
Сарайга керде.

Араларында
Немецлар да бар.
Кызый аларга
Итми ихтибар.

Үләчәген ул
Бит белгән иде.
Төштә әнисен дә
Күргән иде.

Таган астына
Алып килделәр.
Өскә бастырып
Элмәк элделәр.

Карады кызый
Зәңгәрсу күккә.
Яшьләй гомерен
Бирми ул юкка.

Азатлыгыбыз,
Илебез өчен,
Кызганмады ул
Үзенең көчен.

Күз алларында
Үткән гомере.
Җанын алачак
Шул фашист, тәре.

Арада берәү
Хөкем укыды.
Икенчеләре
Чыркага бәрде.

Элмәктә кызый
Калды асылынып.
Халык аһ итте
Нәфрәтен кылып.

Фашистлар киткәч
Кызны алдылар.
Бик саклык белән
Атка салдылар.

Алып кайттылар
Кызны өенә.
Кемнәрдер елый,
Кемдер сөенә.

Икенче көнне
Җирләделәр кызны.
Әнкәсе янына
Кушылды җаны.

Каеннар үсә
Зират эчендә.
Чәчкә куйдылар
Кызыйга көн дә.

Урман кошлары
Сайрый таң белән.
Ел саен кабердә
Яшәрә үлән.

Әлеге авыл
Кыз исемен йөртә.
Поэмам шуның
Белән, дип бетә.

## Эпилог

Бу авылга ел аралаш
Шәһәрдән берәү кайта.
Зират өчләренә кереп
Кабер өстен тазарта.

Чәчләре инде агарган,
Яше сиксән тирәсе.
Монда җирләгән кешеләрне
Оныта алмый күрәсең.

Урман кызының йөрегән
Егеткә дә охшаган.
Бәлкем шулдыр, кем белә бит,
Алайса аңа, нәрсә калган.

Бөек Җиңү бәйрәменең
Алтмыш биш еллыгы быел.
Иншалла үткәрдек без,
Булса да тормыш кыен.

БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# Гади авыл укытучысы

**Язгы кояш үзенең җылы нурларын җир йөзенә сибә башлагач көннәрнең берсендә, 1932 елда Башкортстанның Күгәрчен авылында Гыйльфан һәм Хәерниса гаиләсендә кыз бала үзенең дөньяга килүе турында аваз сала һәм аңа Мәбрүрә исемен бирәләр.**

Мәбрүрә апаның бала чагы табигатьнең урманнарга, чишмәләргә, елгаларга, күлләргә, матур болыннарга, төрле җиләк җимешле аланнарга бай булган җиргә урнашкан авылда уза. Шуңа күрә, ул кечкенәдән шигырьләр язарга ярата. Биш-алты яшендә үк иптәшләре белән уйнаганда, әйтәсе сүзләрен, иптәшләренә рифмалы шигырь юллары белән җавап бирә торган була. Иң беренче шигыре 12 куплеттан, 6-нчы сыйныфта укыганда яза һәм үзе сәхнәдә укый.

Унике яшендә чагында колхоз атларын сугышка алып бетергәч, ул башка балалар белән бер чиратта үзләренең сыерын җигеп, кырларны сабан белән сөрә. Кичләрен утырып фронтка өч бармаклы бияләйләр бәйли, кульяулыклар чигә. Җәйге каникул вакытында олы яшьтәгеләр белән авыр колхоз кырларындагы эшләрне башкара.

«Җиңү көнен ишеткәч, бөтен халык шатланды, ә әтиләре сугыш кырында ятып калган хәбәрен ишеткән иптәшләре җиргә ятып еладылар. Шул минутлар бүгенге көндә дә йөрәкне әрнетәләр, күз алдыннан китмиләр», — дип сөйли Мәбрүрә апа.

Җиденче классны тәмамлагач ул педагогика училищесына укырга керә һәм уңышлы тәмамлагач яшь укытучыны Оренбург өлкәсе, Әсәкәй районының Солтангол авылына укытырга җибәрәләр. Авыл халкы аны бик ярата. Үзенең тырышлыгы, йомшак күңеллеге белән күп кешеләргә үрнәк булып яши бүгенге көндә. Хөкемәтебез тарафыннан бик күп «Мактау грамоталары» ала. Яшь вакытында, мәктәптә эшләгәндә, мәдәният йорты сәхнәсендә спектакльләрдә баш рольләрне башкара. Авыл халкы аның биюләрен, җырларын да көчле алкышлар белән каршы алалар. Басу кырларында алдынгы эшчеләргә үз исемнәре белән багышлап шигырьләр язган. Күптән түгел Бөек Ватан сугышы ветераны булганлыктан, Җиңүнең 65 еллыгына багышланган медаль бирү кичәсендә үзе язган шигырьне укыды. Хәзер Мәбрүрә апа күптән инде лаеклы ялда. Үзенә 78 яшь булса да, ул һәрвакыт шат күңелле, авылдашларына киңәшче, төрле вакытларда ярдәмчел булып яши. Балалары, оныклары, оныкчылары һәрвакыт хәлен белеп, ярдәмләшеп аны шатландырып яшиләр. Озынозак еллар яшәсен иде Мәбрүрә апа Хаирова балаларын һәм авылдашларын сөендереп.

«Читтә булдым, читтә гомер иттем,
Туганнардан ерак яшәдем,
Сер бирмәдем, эштә һәм тормышта
Яшен ташы кебек яшьнәдем», — диеп тәмамлый ул үзе турындагы хатирәләрне.

Укучысы
**Хәфизә СӨЛӘЙМАНОВА.**

**Редакциядән:**
Киләсе санда
Мәбрүрә Хаированың
шигыре басылып чыгачак.

БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# Моңнарга күмелдек

Матвеевка районының Иске Әшер, Иске Котлемәт, Матвеевка авылларында күптән түгел Стәрлетамак шәһәреннән килгән «Сәяхәт» төркеме концерт күрсәтеп киттеләр. Һәр авылда җырчыларның чыгышларын көчле алкышларга күмделәр. Концертны оештыручы Алик Артыхов, җыр башкаручылар Руслан Тимерлан, Ринат Янбаев, биюче Екатерина Кучеренко халыкны моң-сәяхәткә күмеп, таң калдырдылар. Алар башкаруында татар, рус, башкорт, үзбәк, һинд җырлары яңгырады. Концерт бик күңелле үтте. Руслан Тимерлан 1994 елны «Иртәнге йолдыз» программасында катнашып җиңү яулаган. Ә 2010 елны «Туган моңнар» җыр фестиваленең лауреаты булган. Зур рәхмәт «Сәяхәт» төркеменә безне куандырып концерт куйганнары өчен. Киләсе очрашуларны түземсезлек белән көтеп калабыз.

**Фәния КАЛИМУЛЛИНА,**
**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**

# ОБЪЯВЛЕНИЯ

**Уважаемые жители Абдулинского, Асекеевского, Бугурусланского, Матвеевского, Пономаревского, Северного районов!** Продолжается подписка на газету «Туган як. Родной край» с доставкой со следующего месяца. Обратившись в отделение связи или к почтальонам, **вы можете получать газету уже с июля**. Газета выходит два раза в месяц. **Цена символическая.**

Редакция газеты «Туган як. Родной край» готова на взаимовыгодных условиях **сотрудничать** с **рекламодателями** и по их заказу готовить и публиковать тематические статьи и материалы.

**Уважаемые подписчики газеты!** Редакция принимает заявки на публикацию поздравлений, благодарностей и объявлений, в том числе и на татарском языке. Так как газета выходит два раза в месяц, просим делать заявки заблаговременно. Справки по телефонам **8 (353-51) 2-22-81** или **8-93-25-30-73-33.**

Редакция «Туган як. Родной край» с благодарностью **примет спонсорскую помощь** от организаций и частных лиц для издания газеты. Справки о банковских реквизитах по телефонам **8 (35351) 2-22-81** или **8-93-25-30-73-33.**

## УТОЧНЯЕМ

**Некоторые читатели газеты из Пономаревского, Матвеевского и Абдулинского районов жалуются, что работники почты проводят подписку на нашу газету неохотно. А то и вовсе отказывают: мол, такой газеты нет. В связи с этим, сообщаем, что подписка на газету на второе полугодие открыта еще в апреле, согласно договору с областным управлением почтовой связи. В случае отказа подписать газету, просим сообщить об этом в редакцию или в отдел подписки УФПС.**

## ПРОГНОЗ ПОГОДЫ

**8 ИЮНЯ, ВТОРНИК**
Ночью +18. Днем +23.
Ясно. Без осадков.

**9 ИЮНЯ, СРЕДА**
Ночью +10. Днем +26.
Ясно. Без осадков.

**10 ИЮНЯ, ЧЕТВЕРГ**
Ночью +17.Днем +26.
Облачно. Возможен кратковременный дождь.

**11 ИЮНЯ, ПЯТНИЦА**
Ночью +15. Днем +28.
Облачно. Без осадков

**12 ИЮНЯ, СУББОТА**
Ночью +18. Днем +26.
Облачно. Возможны небольшие осадки.

**13 ИЮНЯ, ВОСКРЕСЕНЬЕ**
Ночью +13. Днем +25.
Ясно. Без осадков.

**14 ИЮНЯ, ПОНЕДЕЛЬНИК**
Ночью +11. Днем +22.
Облачно. Возможны осадки.

**15 ИЮНЯ, ВТОРНИК**
Ночью +11. Днем +23.
Облачно. Возможны осадки.

**16 ИЮНЯ, СРЕДА**
Ночью +13. Днем +26.
Облачно. Без осадков



## ПРОГРАММА ТНВ ТАТАРСТАН

ВРЕМЯ МЕСТНОЕ

### 8 ИЮНЯ, ВТОРНИК

8:00 Хэерле иртэ!
10:00 Доброе утро!
11:00 Ганс Христиан Андерсен.
11:45 КГТУ: путь к профессии
12:00 Жырлыйк ?ле
12:45 Колкеханэ
13:00 ТВ фондыннан
13:30 Халкым минем...
14:00 Дамаск хэзинэсе
15:00 Один день из жизни войны
15:30 ТИН-клуб
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Яшьлэр тукталышы
17:15 Мина дус кирэк
17:35 Музыкаль NON-STOP
17:50 Г.Исхакый. «Жан Баевич»
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Сандоканнын кире кайтуы
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Пелагия и белый бульдог.
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Родная земля
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
0:00 КГТУ: путь к профессии
0:05 Ганс Христиан Андерсен.
1:00 Волчица.
2:00 (Ср) Автомобиль
2:30 (Ср) Пелагия и белый бульдог.
3:20 (Ср) Г.Исхакый. «Жан Баевич»
4:10 (Ср) ТВ фондыннан
4:40 (Ср) Жырлыйк әле
5:25 (Ср) Один день из жизни войны

### 9 ИЮНЯ, СРЕДА

8:00 Хәерле иртә!
10:00 Доброе утро!
11:00 Ганс Христиан Андерсен.
11:45 КГТУ: путь к профессии
12:00 Ватандашлар
12:30 Концерт. (Ак кугэрченем)
13:00 Китап
13:30 Яшэсен театр!
14:00 Сандоканнын кире кайтуы
15:00 Среда обитания
15:30 Авентура
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Син — минеке, мин — синеке
17:15 Мина дус кирэк
17:35 Ф. Галиев. «Корт»
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Сандоканнын кире кайтуы
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Пелагия и белый бульдог.
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Кара-каршы
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
0:00 КГТУ: путь к профессии
0:05 Ганс Христиан Андерсен.
1:00 Что сказал покойник.
2:00 (Чт) Видеоспорт
2:30 (Чт) Пелагия и белый бульдог.
3:20 (Чт) Ф. Галиев. «Корт»
4:20 Син — минеке, мин — синеке
4:50 (Чт) Китап

### 10 ИЮНЯ, ЧЕТВЕРГ

8:00 Хәерле иртә!
10:00 Доброе утро!
11:00 Концерт оркестра народных инструментов
11:45 КГТУ: путь к профессии
12:00 Кэеф ничек?
13:00 Үткэннэр сагындыра
13:30 Родная земля
14:00 Сандоканнын кире кайтуы
15:00 Соотечественники
15:30 Авентура
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Мэктэп
17:00 Мультфильм
17:15 Мина дус кирэк
17:35 Музыкаль NON-STOP
17:50 Ф. Галиев. «Корт»
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Сандоканнын кире кайтуы
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Пелагия и белый бульдог.
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Татарлар
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
0:00 КГТУ: путь к профессии
0:05 Таинственные черепа Палау
1:00 Что сказал покойник.
2:00 (Пт) Видеоспорт
2:30 (Пт) Пелагия и белый бульдог. (6-я серия)
3:20 (Пт) Ф. Галиев. «Корт»

### 11 ИЮНЯ, ПЯТНИЦА

7:50 Жомга вэгазе
8:00 Хэерле итртэ!
10:00 Доброе утро!
11:00 Концерт. (Оныта алмыйм)
11:45 КГТУ: путь к профессии
12:00 Мэдэният доньясында
13:00 Татар халык жырлары
13:20 Жомга вэгазе
13:30 Нэсыйхэт
14:00 Сандоканнын кире кайтуы
15:00 Бережно храня
15:15 НЭП
15:30 Авентура
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Мина дус кирэк
17:35 Музыкаль тэнэфес
17:50 Суз иле патшасы
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Сандоканнын кире кайтуы
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Прямая связь
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Адам белэн Хэва
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
0:00 КГТУ: путь к профессии
0:05 Адам женится на Еве

### 12 ИЮНЯ, СУББОТА

4:40 Мутанты
8:00 Татарстан хэбэрлэре
8:15 Новости Татарстана
8:45 Реквизиты былой суеты
9:00 Sина Миннэн Sэлам
11:00 Концерт. («Солнечный» приглашает друзей)
11:40 Мультфильмы
12:00 Каравон-2010
13:00 Мужское дело
13:30 Видеоспорт
14:00 Адымнар
14:30 Яшэсен театр!
15:00 Китап
15:30 Концерт
17:15 Экэмэт кэмит
18:00 Канун. Парламент. Жэмгыять
18:30 Песни военных лет
19:00 КВН-2010
20:00 КВН-2010
20:35 Один день из жизни войны
21:00 Среда обитания
21:30 Концерт. («Оныта алмыйм...»)
22:00 Татарстан. Атналык кузэту
22:30 Жырлыйк эле!
23:15 Страхование сегодня
23:30 Новости Татарстана. В субботу вечером
0:00 Стихи любви
2:10 (Вс) Бои по правилам TNA

### 13 ИЮНЯ, ВОСКРЕСЕНЬЕ

8:00 Татарстан. Атналык кузэту
8:30 Новости Татарстана. В субботу вечером
9:00 Пар канатлар
10:45 Мультфильм
11:00 Концерт. («Чулпан» тобэкара балар ижаты фестивале)
11:45 Мэктэп
12:00 Тамчы-шоу
12:30 Яшьлэр тукталышы
13:00 Грани «Рубина»
13:30 Автомобиль
14:00 Интеллектуальный бум
14:30 Татарлар
15:00 Татар халык жырлары
15:30 В мире культуры
16:30 Концерт. (Как бы танцуя свинг)
17:45 Закон. Парламент. Общество
18:30 Мужское дело
19:00 Кулинарная география.
20:00 Мультфильмы
20:30 7 дней
21:30 Экэмэт кэмит
22:00 Кэеф ничек?
22:45 Елмай!
23:00 Батырлар
23:20 Дорога без опасности
23:30 7 дней
0:30 Видеоспорт
1:00 Выкуп
2:40 (Пн) Эмма
4:20 (Пн) Татар халык жырлары

ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ
E-MAIL:tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:** ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:** С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

ГАЗЕТА ОТПЕЧАТАНА В БУГУРУСЛАНСКОЙ ТИПОГРАФИИ. 461600, г.Бугуруслан, ул.Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**